| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2013 № 10-33/кс

Казан ш.

***«Идел буе экология компаниясе» ҖЧҖ күрсәтә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифны вакытыннан алда яңадан карау турында***

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик дәрәҗә индексларын җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы Карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә «Идел буе экология компаниясе» ҖЧҖ тарафыннан күрсәтелә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифны вакытыннан алда яңадан карарга һәм билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2013 елның 1 октябреннән 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәтләрен күрсәтүче «Идел буе экология компаниясе» ҖЧҖнең җитештерү программасының төп күрсәткечләрен әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән тарифның гамәлдә булу чорына 2 нче кушымта нигезендә килештерергә.

3. «Идел буе экология компаниясе» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 1140 номерлы карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. «Коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында» 2012 елның 30 ноябрендәге 10-34/жкх номерлы Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарына 1 нче

кушымтаның 14 пунктын һәм 4 нче кушымтаның 3 пунктын 2013 елның 1 октябреннән үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
29.08.2013 № 10-33/кс
карарына кушымта № 1

«Идел буе экология компаниясе» ҖЧҖ күрсәтә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү буенча хезмәт күрсәтүләргә тариф

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, коммуналь комплекс оешмасының аталышы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү тарифлары, сум/куб м. |
|---|---|---|
| | Чаллы шәһәре | |
| 1 | «Идел буе экология компаниясе» ҖЧҖ (өстәмә хак салымыннан башка) | 37,00 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.08.2013 № 10-33/кс карарына кушымта № 2

## Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү буенча хезмәт күрсәтүче «Идел буе экология компаниясе» ҖЧҖнең җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасының аталышы | Коммуналь комплекс оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең куб. м | | | | Кирәкле тулай табыш, мең сум (өстәмә хак салымыннан башка) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | |
| | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка төр кулланучылар | |
| 1 | «Идел буе экология компаниясе» ҖЧҖ (өстәмә хак салымыннан башка) | 1320,28 | 992,37 | 69,43 | 258,48 | 48850,33 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм